# Бүләк эзлибез

Җөмһүриятебез мөстәкыйльлеген яулаган елларда миллөтпәрвәр җырчы Рөстәм Маликов, чит-ят төбәкләрдә каңгырап йөргәннән соң, Казаныбызга кайтып төпләнде. Йомшак лирик-тенор тавышы белән ул, уптым илаһи, тамашачыларның мәхәббәтен казанды. Аңа «Италия җырчысы» дигән кушамат тагылды...

Берзаман җырчы үзенең орчык кадәр генә Муса исемле (Роберт, Альфредлар арасында бусы да гаҗәп иде!) өч-дүрт яшьлек улы белән гәзит редакциясенә килеп йөрде. Малайның култык астында кечерәк кенә тальян гармун. Өстәлгә урындык куябыз да, һәркем күрсен өчен, Мусаны шунда меңгереп утыртабыз. Яшь «артист» сыздырып та җибәрә. Үзе уйный, үзе җырлый. Редакция халкын «аһ» иттерә. Хәзер инде Муса Маликов үсеп җитеп, Алманиядә укып, зур музыкант булды. Рөстәмнең җәмәгате Гүзәл ханым балалар ансамбленә җитәкчелек итә. Кече уллары Гайсө дә әти-әнисе, абыйсы юлыннан китеп бара. Музыкаль гаилә, димәк. Яшь талантларның киләчәге алда әле!

Сүзебез бит Башкортстанның атказанган, Татар-станның халык артисты Рөстәм Маликовның үзе хакында. Лирик-тенор тавышлы дигән идек. Ул нигездә опера җырчысы. Татар халык моңнары белән беррөтгән композиторларыбызның опера әсәрләрен дә югары профессиональ кимәлдө башкара. Бүгенге көндә ул милли кадрларыбыз арасында урыс һәм итальян операларындагы арияләрне оста башкаручы буларак танылды.

Бер мисал. Моннан шактый еллар элек Горький тимер юл идарәсе үз хезмәткәрләре турындагы иң яхшы очерк-язмаларга конкурс игълан иткән иде. Анда минем дә бер әсәремне сайлап алганнар. Конкурсны йомгаклау тантанасы Түбән Новгород шәһәрендә үткәрелде. Махсус төзелгән концерт бригадасына Рөстәм Маликов та кертелде. Баянчыбыз Фәрит Хатыйпов. Алга китеп әйтим: атна буена

сузылган концертларда җырчыны сәхнәдән төшермичә алкышларга күмделәр. Татар җырчысының итальян моңнарын шулай оста башкаруы шәһәр җәмәгатьчелеген бинаһая дулкынландырды.

Инде бүләкләргә килик, һаман үзен кыстыра бу димәгез, конкурста абзагызга икенче урын бирелгән иде. Кыйммәтле япон аппаратын күтәреп кайттым. Беренчегә соңгы маркадагы «Волга» автомобиле куелса да, анысына тиң хуҗа табылмады.

– Рөстәм Маликовка булсын! – дидек, бертавыштан.

– Юк, кирәкми, егетләр, – дип, кырт кисте җырчы. – Миңа хәрам ул, чөнки яза белмим. Җырларым өчен берәр төрле премия уйлап чыгарыгыз!

Уйлыйбыз, ник уйламаска?! Бүләге нинди булыр, анысы әлегә тәгаенләнмәгән...

*Гомәр Г. Даһилар мөнбәре. Казан, 2014. 283–284 б.*